ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
САРМАШ_БАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

К А Р А Р

№ 124 **10 декабрь 2024 ел.**

Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерының хезмәткә түләүне оештыру һәм шартлары турында 31.05.2019 ел № 152 Сармаш-Баш авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең 1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Бюджет кодексына ярашлы рәвештә, Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлеге Советының 2019 елның 29 маендагы 152 нче номерлы карары белән расланган “Муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерының хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында нигезләмәнең” (10.09.2020 ел № 177, 24.11.2022 ел № 72, 25.06.2024 ел №111 Сармаш-Баш авыл җирлеге Советының үзгәрешләре һәм өстәмәләре белән), 2.2 пунктына үзгәрешләр кертергә, "Баш бухгалтер" һәм "Бухгалтер" юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Баш бухгалтер	25 700 сум	27 000 сум
Бухгалтер	-	24 500 сум

2. Штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләр кертергә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга " (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлегенең рәсми сайтында.
4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе **Р.М.Фәсхетдинов**